**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Пестречинского**
**муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы**
**Питрәч муниципаль**
**районы**
**башкарма комитеты**
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01 E-mail: pitriash@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«02» июнь, 2021 № 352

«Муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының муниципаль норматив хокукый актларына экспертиза ясау турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 07 маендагы 689 номерлы Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 46 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 9 ноябрендәге 363-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. «Муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының муниципаль норматив хокукый актларына экспертиза ясау турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 07 маендагы 689 номерлы Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертергә:

1) 1.3нче пунктның 5 нче абзацына түбәндәге эчтәлекле пунктча өстәргә:

«3) гадәттән тыш хәлләр режимы гамәлдә булган чорда табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү максатларында эшләнгән норматив хокукый актлар проектлары.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында http://www.-pestreci.tatarstan.ru һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ПЕСТРЕЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

Муниципаль район
башкарма комитеты җитәкчесе А.В.Хәбибуллин